| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

08.05.2018 444-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландыкларны, вакытлыча килештерелгән калдыкларны билгеләү һәм атмосфера һавасына стационар чыганаклардан зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларына рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Экология һәм Табигый ресурслар министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландыкларны, вакытлыча килештерелгән калдыкларны билгеләү һәм атмосфера һавасына стационар чыганаклардан зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларына рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормага салу бүлегенә (С.А.Богатырев) эшләрнең югарыда аталган Регламентка туры китереп башкарылуын тәэмин итәргә.

3. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.Е.Никулин) шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Түбәндәгеләрне көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларына рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 20 апрелендәге 143-п номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә

ташландыкларына рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 23 октябрендәге 420-п номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 07 маендагы 266-п номерлы боерыгының 3, 7 пунктлары;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 24 сентябрендәге 539-п номерлы боерыгының 2 пункты;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2012 елның 20 апрелендәге 143-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларына рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 19 сентябрендәге 925-п номерлы боерыгы.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2018 елның 08 маендагы 444-п номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландыкларны, вакытлыча килештерелгән калдыкларны билгеләү һәм атмосфера һавасына стационар чыганаклардан зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларына рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Регламент хуҗалык һәм бүтән эшчәнлек объектларында урнашкан стационар ташландык чыганакларына ия булган, федераль дәүләт экология күзәтчелегендә тормаучы юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландыкларны, вакытлыча килештерелгән ташландыкларны билгеләү, атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларына рөхсәт бирү, аны үзгәртеп рәсмиләштерү һәм аның гамәлдә булу вакытын яңарту буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

Әлеге Регламентның көче атмосфера һавасына радиоактив матдә ташландыкларына кагылмый.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: шәхси эшкуарлар һәм юридик затлар. Мөрәҗәгать итүчеләр: шәхси эшкуарлар һәм юридик затлар яисә аларның законда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә гамәл кылучы вәкилләре (алга таба – Мөрәҗәгать итүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлык урнашкан урын: Казан ш., Павлюхин ур., 75 й.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре буенча документларны һәм мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен Министрлыкның почта адресы: 420049, Татарстан Республикасы, Казан ш., Павлюхин ур., 75 й.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Гаризалар Министрлыкның эш сәгатьләрендә кабул ителә.

Керү шәхесне таныклый торган документ буенча.

Җәмәгать транспортында килү:

«Филармония» тукталышына кадәр:

№ 2, 4, 5, 12, 25, 31, 37, 43, 47, 69, 69а, 74, 74а, 77 автобуслар;

троллейбуслар: №№ 6, 8, 12;

метро, «Сукно бистәсе» станциясенә кадәр.

1.3.2. Министрлыкның әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормага салу бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоннары: 267-68-81, 267-68-49, 264-49-37. Электрон почта адресы: Sergey.Bogatyrjov@tatar.ru.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайты адресы (алга таба, тиешенчә – Министрлыкның рәсми сайты һәм «Интернет» челтәре): http://eco.tatarstan.ru, электрон почта адресы: eco@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алучы, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www. eco.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.3.5. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 1.3.2, 1.4, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Салым кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1998, № 31, 3824 ст.) (алга таба – Салым кодексы);

«Атмосфера һавасын саклау турында» 1999 елның 4 маендагы 96-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 96-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 18, 2222 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Әйләнә-тирәлекне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 7-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 2, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 2 мартындагы «Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларының һәм аңа карата зарарлы физик йогынтыларның нормативлары турында» № 183 карары (алга таба –

№ 183 РФ Хөкүмәте карары), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2000, № 11, 1180 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 21 апрелендәге «Атмосфера һавасына карата зарарлы йогынтыларны һәм аларның чыганакларын дәүләт исәбенә алу турында нигезләмә раслау хакында» № 373 карары (алга таба – № 373 РФ Хөкүмәте карары), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2000, № 18, 1987 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле объектларны ачыклау криетрияләрен раслау турында» 2015 елның 28 августындагы 903 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 903 номерлы карары), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 07.09.2015, № 36, 5043 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 01 мартындагы 347-р номерлы күрсәтмәсе (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 347-р номерлы күрсәтмәсе) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (WWW.PRAVO.GOV.RU), 2018, 5 март);

Татарстан Республикасы Экология кодексы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2009, № 1, 5 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә), («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

атмосфера һавасы – әйләнә-тирәлекнең торак, җитештерү һәм башка төрле биналардан читтә атмосфера газларының табигый җыелмасыннан гыйбарәт булган яшәеш өчен әһәмиятле компоненты;

зарарлы (пычратучы) матдә – атмосфера һавасында булган һәм билгеле бер катнашмаларда кешенең сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә зарарлы йогынты ясый торган химик яисә биологик матдә яисә шундый матдәләр җыелмасы;

атмосфера һавасын пычрату – атмосфера һавасы сыйфатының дәүләт

тарафыннан билгеләнгән гигиеник һәм экологик нормативларын уздырып җибәрә торган катнашмалардагы зарарлы (пычратучы) матдәләрнең атмосфера һавасына чыгуы яисә барлыкка килүе;

чик күләмдә рөхсәт ителгән ташландык – атмосфера һавасына карата зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыгы нормативы, ул химик матдә күләме яки массасы яисә химик матдәләрнең, микроорганизмнарның, башка төрле матдәләрнең кушылмасы буларак, стационар чыганаклардан һәм (яки) стационар чыганаклар җыелмасыннан атмосфера һавасына ташлау өчен мөмкин булган радиоактив матдәләрнең активлык күрсәткече буларак билгеләнә һәм аны үтәгәндә атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге таләпләрнең үтәлеше тәэмин ителә;

вакытлыча килештерелгән ташландык – атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыгына вакытлыча лимит, ул атмсофера һавасының сыйфатын һәм тиешле территория үсешендәге социаль-икътисадый шартларны исәпкә алып, чик дәрәҗәдә билгеләнгән ташландык күләменә этаплап ирешү максатларында гамәлдәге стационар ташландык чыганаклары өчен билгеләнә;

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм тапшыру, мөрәҗәгать итүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе (алга таба – КФҮ читтән торып эшләү урыны).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамә аңлашыла. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризаларның киңәш ителә торган формалары Регламентка 3, 6, 9 кушымталарда күрсәтелде.

Зарарлы (пычратучы) ташландыкларның чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландыклары (алга таба – ЧМТ) 7 еллык срок белән билгеләнә. ЧМТ ирешүне тәэмин итү шарты белән ташландыкларга рөхсәт ЧМТ гамәлдә булу чорына бирелә.

Әгәр ЧМТ тәэмин ителмәсә, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан билгеләнгән ЧМТ ирешү чорына атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдәләргә вакытлыча килештерелгән ташландыклар (алга таба – ВКТ) билгеләнә. Әлеге очракта ташландыкларга рөхсәтнең гамәлдә булу чоры ташландыкларга рөхсәт бирелгән датадан бер ел тәшкил итә.

Атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) ташландыкларның стационар чыганаклары булган яңа яисә үзгәртеп корылган объектларны эксплуатациягә кертүне гамәлгә ашыручы хуҗалык итүче субъектлар өчен биналарны, корылмаларны һәм бүтән объектларны төзүнең (үзгәртеп коруның) проект документлары составында, шул исәптән төзелеш эшләрен алып бару чорына, расланган ЧМТ булган очракта ташландыкларга рөхсәт расланган проект

документларына туры китереп төзелеш эшләрен алып бару чорына яисә эксплуатациягә кертелә торган яңа яисә үзгәртеп корылган объектларның проект күрсәткечләренә (ләкин иң күбе 2 елга) ирешү чорына бирелә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләп билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атылышы | Чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландыкларны (алга таба – ЧМТ), вакытлыча килештерелгән ташландыкларны (алга таба – ВКТ) билгеләү һәм стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларына рөхсәт (алга таба – рөхсәт) бирү. | № 96-ФЗ Федераль законның 14 ст.; № 7-ФЗ Федераль законның 6, 22, 23 ст.; РФ Хөкүмәтенең № 347-р номерлы күрсәтмәсе; № 183 РФ Хөкүмәте карары белән расланган Нигезләмәнең 9 п.; № 373 РФ Хөкүмәте карары; РФ Хөкүмәтенең № 903 карары; Нигезләмәнең 3.3 пунктының 3.3.7 пунктчасы |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы | № 96-ФЗ Федераль законның 12, 14 ст.; РФ Хөкүмәтенең № 347-р номерлы күрсәтмәсе; РФ Хөкүмәтенең № 183 карары белән расланган нигезләмәнең 9 п.; Нигезләмәнең 3.3 пунктының 3.3.7 пунктчасы |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Билгеләнгән ЧМТ (1 нче кушымта) һәм рөхсәт (2 нче кушымта) яисә ЧМТ билгеләүдән һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат.<br>Билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ һәм рөхсәт яисә ЧМТ һәм ВКТ билгеләүдән һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат.<br>Билгеләнгән ЧМТ кертелгән үзгәрешләр һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәт яисә билгеләнгән | №7-ФЗ Федераль законның 6, 22, 23 ст.;<br>№ 96-ФЗ Федераль законның 12, 14 ст.;<br>РФ Хөкүмәтенең 183 карары белән расланган нигезләмәнең 9, 10 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | ЧМТ үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында хат;<br>Билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ кертелгән үзгәрешләр һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәт яисә билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында хат;<br>Яңартылган рөхсәт яисә рөхсәтнең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында хат. | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәткәндә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры | ЧМТ билгеләү һәм рөхсәт бирү турында гариза килгән вакыттан башлап 34 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.<br>ЧМТ һәм ВКТ билгеләү һәм рөхсәт бирү турында гариза килгән вакыттан башлап 34 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.<br>Билгеләнгән ЧМТ үзгәрешләр кертү һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү гариза килгән вакыттан башлап 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ үзгәрешләр кертү һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүтурында гариза килгән вакыттан башлап 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын яңарту турында гариза килгән вакыттан башлап 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү чорын туктатып тору каралмаган | |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар | ЧМТ билгеләү һәм рөхсәт алу өчен түбәндәгеләр тапшырыла: | РФ<br>бел |

| | | |
|---|---|---|
| нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. ЧМТ билгеләү һәм рөхсәт бирү турында гариза (3 нче кушымта);<br>2. Аерым җитештерү территорияләренең урнашкан урыны турында белешмәләр;<br>3. Атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларын инвентарьлаштыру турында Мөрәҗәгать итүченең имзасы куелган белешмәләр – гамәлдәге хуҗалык яисә бүтән эшчәнлек объектларына карата, яки проект документларындагы белешмәләр – хуҗалык һәм бүтән эшчәнлек буенча төзелә, эксплуатациягә кертелә торган яңа һәм (яки) үзгәртеп корылган объектларга карата;<br>4. Атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларының конкрет һәм тулаем алганда Мөрәҗәгать итүченең яки андагы аерым җитештерү территорияләренең стационар чыганаклары өчен ЧМТ проекты (әлеге Мөрәҗәгать итүченең яки аның аерым җитештерү территорияләренең атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларының барлык чыганакларын исәпкә алып) (алга таба – ЧМТ проекты);<br>5. Атмосфера һавасының фонлы пычрануы турында атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә катнашмаларын исәпләү буенча нигез итеп алынган белешмәләр;<br>6. ЧМТ проектының санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә булуы турында белешмәләр;<br>7. Тапшырыла торган документларның исемлеге. | 9(1<br>РФ |

| | | |
|---|---|---|
| | ЧМТ һәм ВКТ билгеләү һәм рөхсәт алу өчен түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1. ЧМТ һәм ВКТ билгеләү һәм рөхсәт бирү турында гариза (3 нче кушымта);<br>2. Аерым җитештерү территорияләренең урнашкан урыны турында белешмәләр;<br>3. Атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларын инвентарьлаштыру турында Мөрәҗәгать итүченең имзасы куелган белешмәләр – гамәлдәге хуҗалык яисә бүтән эшчәнлек объектларына карата, яки проект документларындагы белешмәләр – хуҗалык һәм бүтән эшчәнлек буенча төзелә, эксплуатациягә кертелә торган яңа һәм (яки) үзгәртеп корылган объектларга карата;<br>4. ЧМТ проекты;<br>5. Атмосфера һавасының фонлы пычрануы турында атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә катнашмаларын исәпләү буенча нигез итеп алынган белешмәләр;<br>6. Атмосфера һавасына зарарлы (пыратучы) матдә ташландыкларын киметү планы (4 нче кушымта) һәм ЧМТ нормативларына этаплап ирешүнең Министрлык раслаган сроклары (ЧМТ нормативларын раслаганда мөрәҗәгать итүченең аларга ирешүе тәэмин ителмәве ачыкланган очракта), шулай ук күрсәтелгән планның тәмамланган этапларын үтәү турында хисап (5 нче кушымта).<br>7. ЧМТ проектының санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә булуы | бел<br>9(1 |

| | | |
|---|---|---|
| | турында белешмәләр;<br>8. Тапшырыла торган документларның исемлеге.<br><br>Билгеләнгән ЧМТ үзгәрешләр кертү һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1. Үзгәрешләр кертүнең һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүнең зарурлык сәбәпләрен күрсәтеп, билгеләнгән ЧМТ үзгәрешләр кертү һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (6 нчы кушымта);<br>2. Билгеләнгән ЧМТ үзгәрешләр кертүнең һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүнең зарурлык сәбәпләрен раслаучы документлар (билгеләнгән ЧМТ һәм/яки рөхсәтнең төп нөсхәсен югалтуга, бозуга бәйле рәвештә ЧМТ үзгәрешләр кертелгән һәм рөхсәт үзгәртеп рәсмиләштерелгән очракта тапшырылмый).<br>3. Элек билгеләнгән ЧМТ һәм мөрәҗәгать итүчегә билгеләнгән тәртиптә элегрәк бирелгән рөхсәтнең төп нөсхәләре (билгеләнгән ЧМТ һәм/яки рөхсәтнең төп нөсхәсен югалтуга, бозуга бәйле рәвештә рөхсәт үзгәртеп рәсмиләштерелгән очракта тапшырылмый).<br>4. Җитештерү процессының, чимал һәм материаллар сарыфының, чыгарыла торган продукциянең (хезмәт күрсәтүләрнең) номенклатурасы һәм күләмнәре, атмосфера һавасына ташландык чыганакларының сыйфатламаларының үзгәрмәүчәнлеге турында дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан имзаланган белешмә. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ үзгәрешләр кертү һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1. Үзгәрешләр кертүнең һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүнең зарурлык сәбәпләрен күрсәтеп, билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ үзгәрешләр кертү һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза (6 нчы кушымта);<br>2. Билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ үзгәрешләр кертүнең һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүнең зарурлык сәбәпләрен раслаучы документлар (билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ һәм/яки рөхсәтнең төп нөсхәсен югалтуга, бозуга бәйле рәвештә ЧМТ һәм ВКТ үзгәрешләр кертелгән һәмрөхсәт үзгәртеп рәсмиләштерелгән очракта тапшырылмый).<br>3. Элек билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ һәм мөрәҗәгать итүчегә билгеләнгән тәртиптә элегрәк бирелгән рөхсәтнең төп нөсхәләре (билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ һәм/яки рөхсәтнең төп нөсхәсен югалтуга, бозуга бәйле рәвештә рөхсәт үзгәртеп рәсмиләштерелгән очракта тапшырылмый).<br>4. Җитештерү процессының, чимал һәм материаллар сарыфының, чыгарыла торган продукциянең (хезмәт күрсәтүләрнең) номенклатурасы һәм күләмнәре, атмосфера һавасына ташландык чыганакларының сыйфатламаларының үзгәрмәүчәнлеге турында дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан имзаланган белешмә. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Рөхсәтне яңарту өчен түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1. Рөхсәтне яңарту турында гариза (9 нчы кушымта);<br>2. Нигезләүче документларны теркәп, рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып торуга китереп чыгарган шартларны бетерүгә документаль раслама.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>почта юлламасы белән.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен | 1. ЧМТ проекты буенча санитар-эпидемиологик бәяләмә һәм эксперт бәяләмәсе (Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсендә). | № [illegible]<br>1 ө[illegible] |

| | | |
|---|---|---|
| зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | 2. Рөхсәт бирелгән өчен дәүләт пошлинасын түләүне раслаучы документ (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында);<br>3. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсендә).<br>4. Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсендә).<br>Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән мөмкинлек булганда электрон рәвештә дә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Мөрәҗәгать итүчедән югарыда санап үтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| килештерү таләп ителә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртүче вәкилләрнең вәкаләтләрен раслаучы законда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең тапшырылмавы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>ЧМТ билгеләүдән һәм рөхсәт бирүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:<br>- әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;<br>- Мөрәҗәгать итүченең объекты федераль дәүләт экология күзәтчелегенә кертелүе;<br>- рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы түләвенең булмавы;<br>- тулы булмаган, төгәл булмаган яисә ялган мәгълүмат тапшырылуы;<br>- атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларын инвентарьлаштыру буенча | РФ<br>бел<br>(6)<br>кар |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырылган белешмәләрнең төгәл булмавы турында (ташландыкларның исәп һәм сыйфат составы турында, шулай ук ташланлык чыганакларының сыйфатламалары турында) атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге нәтиҗәләре белән расланган белешмәләр булуы;<br>- ЧМТ проектын эшләгәндә кулланыла торган белешмәләренең проект документлары белешмәләренә (хуҗалык һәм бүтән эшчәнлек буенча төзелә торган, эксплуатациягә кертелә торган һәм яңа һәм (яисә) үзгәртеп корылган объектларга карата) яисә атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларын инвентарьлаштыру белешмәләренә (гамәлдәге хуҗалык һәм бүтән эшчәнлек объектларына карата) туры килмәве, шул исәптән ташлана торган зарарлы (пычратучы) матдәләрнең тулы булмаган исемлеге күрсәтелүе;<br>- чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландыклар-ның эшләнгән нормативларында (үзгәрү ялгышларын исәпкә алып) арифметика хаталары булуы;<br>- чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландыклар-ның эшләнгән проектларында ташландык күләме яисә массасы чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландык-ларны артып китә торган матдәләрнең булуы.<br><br>ЧМТ һәм ВКТ билгеләүдән һәм рөхсәт бирүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:<br>- әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның | РФ<br>бел<br>9(6 |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырылмавы;<br>- Мөрәҗәгать итүченең объекты федераль дәүләт экология күзәтчелегенә кертелүе;<br>- рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы түләвенең булмавы;<br>- тулы булмаган, төгәл булмаган яисә ялган мәгълүмат тапшырылуы;<br>- атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларын инвентарьлаштыру буенча тапшырылган белешмәләрнең төгәл булмавы турында (ташландыкларның исәп һәм сыйфат составы турында, шулай ук ташланлык чыганакларының сыйфатламалары турында) атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге нәтиҗәләре белән расланган белешмәләр булуы;<br>- ЧМТ проектын эшләгәндә кулланыла торган белешмәләренең проект документлары белешмәләренә (хуҗалык һәм бүтән эшчәнлек буенча төзелә торган, эксплуатациягә кертелә торган һәм яңа һәм (яисә) үзгәртеп корылган объектларга карата) яисә атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларын инвентарьлаштыру белешмәләренә (гамәлдәге хуҗалык һәм бүтән эшчәнлек объектларына карата) туры килмәве, шул исәптән ташлана торган зарарлы (пычратучы) матдәләрнең тулы булмаган исемлеге күрсәтелүе;<br>- чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландыклар-ның эшләнгән нормативларында (үзгәрү ялгышларын исәпкә алып) арифметика хаталары булуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| | - Министрлык тарафыннан расланган МЗТ нормативларына этаплап тапшыру вакытлары булмау;<br>- мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән вакытларда аның буенча ВКТ билгеләнә торган һәр матдә буенча ЧМТ нормативларына этаплап ирешүне тәэмин итә торган атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын киметү планнарының, Министрлык тарафыннан расланган ЧМТ нормативларына этаплап ирешү вакытларының үтәлмәве, яисә тормышка ашырылган чараларның планлаштырылган нәтиҗәләренә ирешелмәве;<br>- планның ахыргы күрсәткечләре сыйфатында чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландыкларны артып китә торган зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларының яисә массаларының күрсәтелүе.<br>Билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:<br>- әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;<br>- мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда нинди дә булса белешмәләрнең җитешмәве яки аларда төгәл булмаган белешмәләр булуы.<br>Рөхсәтне яңартудан баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:<br>- әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы; | |

| | | |
|---|---|---|
| | - мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда нинди дә булса белешмәләрнең җитешмәве яки аларда төгәл булмаган белешмәләр булуы. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Рөхсәт биргән өчен 3500 сум күләмендә дәүләт пошлинасы алына.<br>Дәүләт пошлинасын күчерү өчен реквизитлар:<br>Р/с 40101810800000010001<br>Алучының банкы – Татарстан Республикасы МБ бүлеге<br>Банк БИК 049205001<br>Алучы: ТР буенча ФКИ (ТР Экология министрлыгы)<br>Алучының ИНН 1659036508<br>Алучының КПП 165901001<br>Бюджет классификациясе коды:<br>701 1 08 07262 01 1000 110<br>Рөхсәт алу өчен дәүләт пошлинасын түләгәндә түләү йөкләмәсендәге «Түләүнең билгеләнеше»ндә түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк: Атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыклары өчен рөхсәт бирү өчен дәүләт пошлинасы | Са<br>116<br>зак |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү күздә тотылмый | |

| | | |
|---|---|---|
| турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамә тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Рөхсәт алу буенча кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамәсен, шул исәптән электрон рәвештә теркәү вакыты | Гариза кергән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм | Дәүләт хезмәте һаваны кондиционерлау системасы, янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазланган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| мультимедияле мәгълүматлар урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу-булмавы күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә керү саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарыда алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүматлар алу мөмкинлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәләрен гариза белән документларны электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырганда мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында алу мөмкинлеге (гариза белән документларны электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеген тормышка ашыргач); | Тәр<br>пун |

| | | |
|---|---|---|
| | инвалидларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>әлеге Регламентны дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бозуларга карата прецендентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы (прецендентларның, шикаятьләрнең Министрлыкның һәм Министрлыктагы территориаль идарәләрнең дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гомуми санына нисбәте);<br>мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле гариза белән документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша җибәргәндә:<br>1. әгәр гариза белән документларның | |

| | | |
|---|---|---|
| | күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, – турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми;<br>2. әгәр гариза белән документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, – бер мәртәбәдән артык түгел.<br>Мөрәҗәгать итүче белән бер мәртәбә эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://www.eco.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Билгеләнгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм рөхсәт алынган очракта документларның төп нөсхәләрен алга таба күрсәтеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны һәм сканер аша чыгарылган документларны электрон рәвештә, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеге бар | №<br>№ |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

Чик дәрәҗәдә мөмкин булган ташландыкларны, вакытлыча билгеләнгән ташландыкларны билгеләү һәм стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыклары өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен үтәү кысаларында түбәндәге процедуралар гамәлгә ашырыла:

ЧМТ билгеләү һәм рөхсәт бирү яисә ЧМТ билгеләүдән һәм рөхсәт бирүдән баш тарту;

ЧМТ һәм ВКТ билгеләү һәм рөхсәт бирү яисә ЧМТ һәм ВКТ билгеләүдән һәм рөхсәт бирүдән баш тарту;

билгеләнгән ЧМТ үзгәрешләр кертү һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү яисә билгеләнгән ЧМТ үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп корудан баш тарту;

билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ үзгәрешләр кертү һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү яисә билгеләнгән ЧМТ һәм ВКТ үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту;

рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын яңарту яисә яңартудан баш тарту.

3.1.1. ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләү һәм рөхсәт бирү буенча административ процедуралар түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) мөрәҗәгать итүче тапшырган материалларның комплектлылыгын тикшерү, мөрәҗәгать итүче материалларын карау, ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм рөхсәт (ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләүдән һәм рөхсәт бирүдән баш тарту) әзерләү һәм раслау.

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

6) техник хатаны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге турында блок-схема әлеге Регламентның 11 нче кушымтасында күрсәтелде.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче Министрлыкның әйләнә-тирәлеккә йогынтыны нормага салу бүлегенә (алга таба – Бүлек) шәхсән, почта аша, телефоннан, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) порталы аша һәм (яки) электрон

почта ярдәмендә дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече шәхсән, телефоннан, электрон почта һәм (яки) хат белән, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның рәвеше һәм эчтәлеге буенча һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән аны рәсмиләштерү өлешендә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның рәвеше буенча һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләрдә консультацияләү, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән кәгазьдә, рөхсәт алган очракта документларның төп нөсхәләрен алга таба күрсәтеп, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә яисә почта юлламасы белән әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны (алга таба – документлар) теркәп, гаризаны документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә тапшыра (җибәрә).

Гариза электрон формада җибәрелгән очракта сорала торган документларның сканер аша чыгартылган күчермәләре теркәлә, гариза заказлы почта юлламасы итеп җибәрелгәндә, – дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан таныкланган документлар.

Гариза тапшыру мөрәҗәгать итүчедән документлар рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк аша һәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша күрсәтелми.

3.3.2. Документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза белән документларны кабул итә;

гаризаны гаризаларны теркәү дәфтәрендә терки (электрон рәвештә);

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү датасы турында тамга куеп, гариза күчермәсен тапшыра;

каралуын оештыру өчен гаризаны һәм документларны әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормага салу бүлеге (алга таба – Бүлек) башлыгына тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән, Бүлек башлыгына тапшырылган документлар.

3.3.3. Җаваплы вазыйфаи затны билгеләү.

Бүлек башлыгы гаризаны һәм документларны карау өчен җаваплы башкаручы (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм тапшырылган материалларны аңа тапшыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә тапшырылган документлар.

3.4. Ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә гарызнамәләр җибәрә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр бирү турында, – Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә;

ЧМТ проекты буенча санитар-эпидемиологик бәяләмә һәм эксперт бәяләмәсе бирү турында, – Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенә;

атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыклары өчен рөхсәт бирүгә дәүләт пошлинасы түләнүен раслаучы документ бирү турында, – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментына.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турындагы гарызнамәләр.

Сорала торган документлар (белешмәләр) белешмәләрне җиткерүче тарафыннан законнарда билгеләнгән вакытларда җибәрелгән гарызнамәләр нигезендә тапшырыла.

3.5. Мөрәҗәгать итүче тапшырган материалларның комплектлылыгын тикшерү, мөрәҗәгать итүче материалларын карау, ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм рөхсәт (ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләүдән һәм рөхсәт бирүдән баш тарту) әзерләү һәм билгеләү;

3.5.1. Бүлек белгече килгән документларны әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, комплектлы булу-булмавын тикшерә.

Килгән белешмәләр әлеге Регламентның 2.5 п. таләпләренә җавап бирмәгән очракта, Бүлек белгече:

ике нөсхәдә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли һәм аны документлар белән бергә килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрә;

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гарызнамәләргә җаваплар килгәннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ике нөсхәдә, килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проектлары, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

3.5.2. Бүлек башлыгы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын килештерә һәм аны документлар белән имза кую өчен Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормага салу идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән, кул кую өчен Идарә башлыгына җибәрелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты.

3.5.3. Идарә башлыгы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын килештерә һәм аны документлар белән министрның беренче урынбасарына кул кую өчен җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында ике нөсхәдә килештерелгән, имза кую өчен министрның беренче урынбасарына юлланган хат проекты.

3.5.4. Министрның беренче урынбасары дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында ике нөсхәдә хат проектына кул куя һәм аны документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.5.2-3.5.4 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.1 пунктындагы процедура тәмамланганнан соң өч эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында ике нөсхәдә кул куелган, документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә җибәрелгән хат проекты.

3.5.5. Документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече:

хатны ведомствоара документ әйләнеше системасында терки һәм аның бер нөсхәсен мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән тору адресы буенча җибәрә;

хатның икенче нөсхәсен саклау өчен Министрлык архивына җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән хат, аның беренче нөсхәсе почта буенча мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән, икенче нөсхәсе Министрлык архивына җибәрелгән.

3.5.6. Бүлек белгече белешмәләр әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры килгән очракта:

тапшырылган документларның табигать саклау законнары таләпләренә җавап бирү-бирмәвен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, мөрәҗәгать итүчегә кисәтүләрне бетерү зарурлыгы турында аларны бетерү срокларын күрсәтеп, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып хәбәр итә;

әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаганда, ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләү турында ике нөсхәдә документ проекты, ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләү һәм рөхсәт алу өчен материалларны карау нәтиҗәләре буенча Министрлык проекты белән ике нөсхәдә рөхсәт проектын әзерли;

өстәмә эшләп бетергәннән соң документларда әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, ике нөсхәдә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли;

ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләү турында документны ике нөсхәдә, Министрлык бәяләмәсе белән рөхсәт проектын ике нөсхәдә яисә баш тарту турында хат проектын килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4 пунктындагы процедура тәмамланганнан соң 25 эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләү турында документ проекты, Министрлык бәяләмәсе проекты белән рөхсәт проекты яисә баш тарту турында хат проекты.

3.5.7. Бүлек башлыгы ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләү турында документ проектын, Министрлык бәяләмәсе проекты белән рөхсәт проектын яки баш тарту турында хат проектын карый, килештерә һәм кул кую өчен Идарә башлыгына җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә башлыгына килештерү өчен җибәрелгән, Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләү турында документ проекты, Министрлык бәяләмәсе проекты белән рөхсәт проекты яисә баш тарту турында хат проекты.

3.5.8. Идарә башлыгы ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләү турында документ проектын, Министрлык бәяләмәсе проекты белән рөхсәт проектын яки баш тарту турында хат проектын карый, килештерә һәм кул кую өчен министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.5.7-3.5.8 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә башлыгы тарафыннан килештерелгән, министрның беренче урынбасарына җибәрелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләү турында документ проекты, Министрлык бәяләмәсе проекты белән рөхсәт проекты яисә баш тарту турында хат проекты.

3.5.9. Министрның беренче урынбасары ике нөсхәдәге ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ), рөхсәт проектына һәм ике нөсхәдәге Министрлык бәяләмәсенә яисә ике нөсхәдәге дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатка (7 нче кушымта) кул куя, ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм рөсхәтне Министрлык мөһере белән таныклый һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган ике нөсхәдә ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ), ике нөсхәдә рөхсәт һәм ике нөсхәдә Министрлык бәяләмәсе һәм ике нөсхәдә баш тарту турында хат.

3.5.10. ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләү һәм рөхсәт бирү турында яисә ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләүдән һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында мәгълүматны тиешле мәгълүмат ресурсына кертү һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләү һәм рөхсәт бирү өчен тапшырылган документларны һәм материалларны Министрлык архивына тапшыру.

Бүлек белгече:

билгеләнгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм рөхсәткәт теркәлү номерларын беркетә;

ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләү һәм рөхсәт бирү турында яисә ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) билгеләүдән һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында мәгълүматны Министрлыкның Бердәм бүленгән мәгълүмати-аналитик системасына (ББМАС) кертә;

билгеләнгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм рөхсәтнең икенче нөсхәсен һәм Министрлык бәяләмәсенең икенче нөсхәсен яки баш тарту турында хатның икенче нөсхәсен саклау өчен архивка тапшыра;

баш тарту турында хатның беренче нөсхәсен документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә тапшыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ББМАС кертелгән мәгълүмат, Министрлык архивына юнәлдерелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм рөхсәтнең икенче нөсхәсе һәм Министрлык бәяләмәсенең икенче нөсхәсе яки баш тарту турында хатның икенче нөсхәсе, документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә тапшырылган баш тарту турында хатның беренче нөсхәсе.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

3.6.1. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә Министрлык бәяләмәсенең бер нөсхәсен, ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) бер нөсхәсен һәм рөхсәтнең бер нөсхәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган Министрлык бәяләмәсенең бер нөсхәсе, ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) бер нөсхәсе һәм рөхсәтнең бер нөсхәсе.

3.6.2. Рөхсәт бирүдән баш тарткан очракта, документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече баш тарту турында хатны ведомствоара документ әйләнеше системасында терки һәм аны мөрәҗәгать итүчегә аның торган урыны буенча гаризада күрсәтелгән адрес буенча җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура 3.5.10 пунктчада билгеләнгән процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән, почта аша мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән хат.

3.7. Билгеләнгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертү һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү буенча административ процедура әлеге Регламентның 3.1.1 п. нигезендәге процедураларны үз эченә ала.

3.7.1. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү әлеге Регламентның 3.2 п. нигезендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтен алу тәртибе буенча консультацияләр.

3.7.2. Гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итү һәм теркәү. Җаваплы вазыйфаи затны билгеләү.

Билгеләнгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертү һәм стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычратучы) матдә ташландыкларына рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен, түбәндәге очракта:

- юридик затның аталышы, шул исәптән фирма исеме, юридик затның оешу-хокук формасы, аның урнашкан урыны, юридик затны теркәүгә алу турында язуның дәүләт теркәвенә алыну номеры һәм юридик зат турында язуның Юридик

затларның бердәм дәүләт реестрына кертелү фактын раслаучы документ белешмәләре үзгәртелгәндә, – юридик зат өчен;

шәхси эшкуарның фамилиясе, аның яшәгән урыны, аның шәхесен таныклаучы документ белешмәләре, шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алу турында язуның дәүләт теркәвенә алу номеры һәм шәхси эшкуар турында язуның Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертелү фактын раслаучы документ белешмәләре үзгәртелгәндә, – шәхси эшкуар өчен;

ташландыкларга рөхсәт бозылганда яисә югалганда
мөрәҗәгать итүче шәхсән кәгазьдә, рөхсәт алган очракта документларның төп нөсхәләрен алга таба күрсәтеп, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә яисә тапшырылуы турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, билгеләнгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертү һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гаризаны документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә тапшыра (җибәрә).

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү, җаваплы башкаручыны билгеләү әлеге Регламентның 3.3.2-3.3.3 пунктчалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7.3. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада гарызнамәләр җибәрү әлеге Регламентның 3.4 пунктына туры китереп гамәлгә ашырыла.

3.7.4. Мөрәҗәгать итүче тапшырган материалларның комплектлылыгын тикшерү, мөрәҗәгать итүче материалларын карау, билгеләнгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләрне әзерләү һәм раслау һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәтне имзалау (ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту).

Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

килгән белешмәләрне әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

килгән белешмәләр туры килгән очракта – ике нөсхәдә үзгәртелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм ике нөсхәдә Министрлык бәяләмәсе проекты белән рөхсәт проектын әзерли.

килгән белешмәләр туры килмәгән очракта – ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында ике нөсхәдә хат проектлары әзерли;

үзгәртелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм Министрлык бәяләмәсе белән рөхсәт проектын яисә ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында хат проектын килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Килгән белешмәләр документларда күрсәтелгән белешмәләргә туры килмәгән очракта әлеге Регламентның 3.5.1 пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач дүрт эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: үзгәртелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм Министрлык бәяләмәсе проекты белән үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәт проекты яисә ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында (мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итеп) хәбәрләмә.

3.7.5. Бүлек башлыгы үзгәртелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм Министрлык бәяләмәсе белән рөхсәт проектын яисә ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында хат проектын карый, килештерә һәм имза кую өчен Идарә башлыгына җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен Идарә башлыгына җибәрелгән үзгәртелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм Министрлык бәяләмәсе белән рөхсәт проекты яисә ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында хат проекты.

3.7.6. Идарә башлыгы үзгәртелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм Министрлык бәяләмәсе белән рөхсәт проектын яисә ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында хат проектын карый, килештерә һәм имза кую өчен министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.7.5-3.7.6 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзалау өчен министрның беренче урынбасарына юлланган үзгәртелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм Министрлык бәяләмәсе белән рөхсәт проекты яисә ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында хат проекты.

3.7.7. Министрның беренче урынбасары үзгәртелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм Министрлык бәяләмәсе белән үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәткә яки ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында хатка кул куя, ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм рөхсәтне Министрлык мөһере белән таныклый һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: үзгәртелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм Министрлык бәяләмәсе проекты белән үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәт яисә ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында хат.

3.7.8. ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертелүе һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында яки ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында мәгълүматларны тиешле мәгълүмат ресурсына кертү һәм дәүләт хезмәтен алу өчен мөрәҗәгать итүче тапшырган документларны һәм материалларны Министрлык архивына тапшыру.

Бүлек белгече:

үзгәртелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм рөхсәткә элек билгеләнгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм бирелгән рөхсәтнең теркәлү номерына туры килә торган теркәлү номерын (тиешле П литерын өстәп), үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәттә күрсәтелгән гамәлдә булу срогын күрсәтеп беркетә;

элек билгеләнгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм ташландыкларга бирелгән рөхсәт бланкларын мөрәҗәгать итүче материалларына терки һәм саклау өчен архивка тапшыра;

ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертелүе һәм рөхсәтнең үзгәртеп рәсмиләштерелүе турында мәгълүматны ББМАС кертә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: архивка тапшырылган документлар, ББМАС кертелгән мәгълүмат.

3.7.9. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә яки аның ышанычлы затына үзгәртелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм бәяләмә белән үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәтне яисә ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында хатны (8 нче кушымта), сәбәпләрен күрсәтеп, тапшыра (җибәрә).

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) үзгәртелгән ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) һәм бәяләмә проекты белән үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәт яисә ЧМТ (ЧМТ һәм ВКТ) үзгәрешләр кертүдән һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында хат.

3.8. Рөхсәтнең гамәлдә булуын яңарту буенча административ процедура әлеге Регламентның 3.1.1 п. туры китерелгән процедураларны үз эченә ала.

3.8.1. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү әлеге Регламентның 3.2 п. нигезендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтен алу тәртибе буенча консультацияләр.

3.8.2. Гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итү һәм теркәү. Җаваплы вазыйфаи затны билгеләү.

Ташландыкларга рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып торуга китереп чыгарган шартларны бетерү очрагында, мөрәҗәгать итүче рөхсәт дубликатын бирү өчен шәхсән кәгазьдә, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә, алга таба рөхсәт алынган очракта документларның төп нөсхәләрен күрсәтеп, яисә кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән почта аша әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гаризаны документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә тапшыра (җибәрә).

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү, җаваплы башкаручыны билгеләү әлеге Регламентның 3.3.2-3.3.3 пунктчалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.3. Бүлек белгече:

рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып торуга китереп чыгарган җитешсезлекләрне бетерү фактлары турында тапшырылган мәгълүматны карый;

ташландыкларга рөхсәтнең гамәлдә булуын яңарту турында яисә рөхсәтнең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында карар кабул итә;

рөхсәтнең гамәлдә булуын яңарту турында яисә рөхсәтнең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында мөрәҗәгать итүче адресына хат проекты әзерли;

рөхсәтнең гамәлдә булуын яңарту турында мәгълүмат белән Министрлыкның территориаль идарәсенә хат проекты әзерли (уңай карар кабул ителгән очракта);

хат проектларын килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач дүрт эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән хат проектлары.

3.8.4. Бүлек башлыгы хат проектларын карый, килештерә һәм имза кую өчен Идарә башлыгына юллый.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән хат проектлары.

3.8.5. Идарә башлыгы хат проектларын карый, килештерә һәм кул кую өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән хат проектлары.

3.8.6. Министрның беренче урынбасары мөрәҗәгать итүче адресына рөхсәтнең гамәлдә булуын яңарту турында яисә рөхсәтнең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында хатка һәм ташландыкларга рөхсәтнең гамәлдә булуын яңарту турында мәгълүмат белән Министрлыкның территориаль идарәсенә булган хатка (уңай карар кабул ителгән очракта) кул куя. Имзаланган хатлар документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә җибәрелә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Имзаланган, документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә җибәрелгән хатлар.

3.8.7. Документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече:

рөхсәтнең гамәлдә булуын яңарту турында (8 нче кушымта) яки рөхсәтнең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында хатны терки һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә;

ташландыкларга рөхсәтнең гамәлдә булуын яңарту турында мәгълүмат белән Министрлыкның территориаль идарәсенә булган хатны (уңай карар кабул ителгән очракта) терки.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә һәм Министрлыкның территориаль органына җибәрелгән рөхсәтнең гамәлдә булуын яңарту турында яисә рөхсәтнең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында хатлар.

3.8.8. Бүлек белгече рөхсәтнең гамәлдә булуын яңарту турында мәгълүматны ББМАС системасына кертә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ББМАС кертелгән мәгълүмат.

3.9. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк, КФҮ читтән торып эшләү урыны аша күрсәтү тәртибе.

Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәктә, КФҮ читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.

3.10. Техник хаталарны (язу, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү

3.10.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турында гариза (10 нчы кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хаталары) булган документ;

техник хатасы (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хатасы) барлыгын дәлилли торган документлар.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкиле)тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә), яисә Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә.

3.10.2. Министрлыкның документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән бергә бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша электрон рәвештә терки.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен җибәрелгән гариза.

3.10.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкиленә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкиленнән) техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның чын нөсхәсен алып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша Министрлыкка техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның чын нөсхәсен тапшырган очракта документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) ачыклангannan соң яки теләсә нинди кызыксынган заттан җибәрелгән техник хатасы (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хатасы) турында гариза алынганнан соң өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору түбәндәгеләрне үз эченә ала: мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, шикаятьләр карау, тикшерүләр уздыру, мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү, Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләү.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырылганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән административ процедуралар башкарылуны тикшереп тору максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. ДӘүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануы буенча агымдагы контрольлек Бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Министр (министрның беренче урынбасары) мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре вакытында каралуын тикшерүдә тота.

4.4. Регламент үтәлешен гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан тикшереп тору Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләрне (гамәл кылмауны) һәм карарларны иң югары торучы дәүләт хакимияте органнарына шикаять кылу юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче Министрлыкның, шулай ук аның дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затының, дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының, Министрлыктагы дәүләт граждан хезмәткәренең гамәлләрен (гамәл кылмавын) Министрлыкка шикаять итәргә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

